**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.08.2023 №1528

Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «Кама Тамагы муниципаль районы «Акчарлак» спорт-савыктыру комплексы» муниципаль бюджет учреждениесендә түләүле хезмәтләр турында» 2015 елның 12 мартындагы 76 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 4 п.1 п. нигезендә, «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 04 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль законның 9,9.1 ст. һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2005 елның 8 декабрендәге 19 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Уставының 7 ст.1 п. 27 пунктчасы нигезендә (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән), Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Акчарлак» спорт-савыктыру комплексы» муниципаль бюджет учреждениесендә түләүле хезмәтләр турында» 2015 елның 12 мартындагы 76 номерлы карарының 1 нче кушымтасын яңа редакциядә әлеге карарга кушымта нигезендә бәян итәргә.

2. Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «Кама Тамагы муниципаль районы «Акчарлак» спорт-сәламәтләндерү комплексы» муниципаль бюджет учреждениесендә түләүле хезмәтләр күрсәтү турында» 2015 елның 12 мартындагы 76номерлы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының

карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 2 ноябрендәге 1149 номерлы карарын  үз көчен югалткан дип санарга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасары М.Х.Хәбибулловага йөкләргә.

Җитәкче Р.М. Заһидуллин

Кама Тамагы муниципаль районы
Башкарма комитетының 2015 елның 12 мартындагы 76 номерлы карарына 1 нче кушымта
от 24.08.2023 № 1528

**« Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Акчарлак» спорт-савыктыру комплексы» муниципаль бюджет учреждениесенең түләүле хезмәтләре бәясе**

| № т/б | Хезмәт күрсәтү атамасы | 1тапкыр керү дәвамлылыгы (мин) | Бәясе (сум) | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 10.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр | 17.00 сәгатьтән 22.00 сәгатькә кадәр |
| 1. | "Бассейн" зурлар абонементы:<br>Лимитсыз бер айга<br>- 1 айга 8 тапкыр килү<br>- 1 айга 4 тапкыр килү<br>- бер тапкыр килү | <br><br>60<br>60<br>60 | <br>1400-00<br>880-00<br>440-00<br>130-00 | <br>1400-00<br>880-00<br>440-00<br>130-00 |
| 2. | "Бассейн-сауна" зурлар абонементы:<br>- бер тапкыр килү | 60 | 250-00 | 250-00 |
| 3. | "Бассейн-Тренажер залы" зурлар абонементы:<br>Бер айга лимитсыз | | 1600-00 | 1600-00 |
| 4. | Зурлар өчен "Тренажерный зал" абонементы:<br>Бер айга лимитсыз<br>- Айга 8 дәрес<br>- Айга 4 дәрес<br>- бер тапкыр | <br><br>60<br>60<br>60 | <br>1100-00<br>880-00<br>440-00<br>130-00 | <br>1100-00<br>880-00<br>440-00<br>130-00 |
| 5. | Зурлар өчен "Фитнес" :<br>- бер тапкыр | 60 | 110-00 | 110-00 |
| 6. | Теннис<br>- бер тапкыр килү | 60 | 110-00 | 110-00 |
| 7. | Турмания жилеты | 40 | 80-00 | 80-00 |
| 8. | "Икенче йөрәк" аппараты | 12 | 50-00 | 50-00 |
| 9. | МИО стимуляторы поясы | 40 | 50-00 | 50-00 |
| 10. | Nuga-Best массаж караваты (1 сеанс) | 40 | 100-00 | 100-00 |
| 11. | Бильярд | 60 | 180-00 (өстәл артына) | 180-00 (өстәл артына) |
| 12. | Аренда:<br>- уен залы<br>- сауна белән бассейн (25 кешегә кадәр) | <br>60<br>60 | <br>1200-5000,00<br>3300-00 | <br>1200-5000,00<br>3300-00 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 13. | Кунакханә хезмәтләре:<br>- Кунакханә - люкс (1 кеше)<br>- Кунакханә (1 кеше) | тәүлек<br>тәүлек | 700-00<br>500-00 | 700-00<br>500-00 |
| 14. | Прокат:<br>Йөзү йчен башлыклар<br>Йөзү өчен күзлекләр<br>Жилет<br>Ластлар | һәр предмет өчен | 50-00<br>50-00<br>50-00<br>50-00 | 50-00<br>50-00<br>50-00<br>50-00 |
| 15. | Прокат:<br>Сөлге<br>Простыня | һәр предмет өчен | 60-00<br>60-00 | 60-00<br>60-00 |
| 16. | Бахил сату | 1 пар | 5-00 | 5-00 |

**«Акчарлак ССК» МБУ бассейнында бушлай йөрү (1 кешегә 1 сәгать дәвамлылык)**

1. Күпбалалы һәм аз керемле гаиләләрдән 16 яшькә кадәрге балалар - атнага 1 тапкыр (якшәмбе);
2. 16 яшькә кадәрге балалар - ятим һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар - атнага 1 тапкыр (якшәмбе);
3. Балачак инвалидлары;
4. Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм инвалидлары;

**Льготалар (1 кешегә 1 сәгать дәвамлылык) «Акчарлак ССК» МБУ бассейнына бару өчен 10:00 дән 22:00 сәгатькә кадәр:**

1. 3 яшькә кадәрге балалар бушлай;
2. 4 яштән 16 яшькә кадәрге балалар - 80 сум;
3. СССР территориясендә, Россия Федерациясе территориясендә һәм башка дәүләтләр территориясендә сугышчан хәрәкәтләр ветераннары - 100 сум;
4. Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнар - 100 сум;
5. Раслаучы документ һәм паспорт биргәндә пенсионерлар - 100 сум;
6. Гомуми белем бирү учреждениеләренең мәктәпкәчә һәм мәктәп яшендәге 4 яштән 16 яшькә кадәрге балалар бассейнына һәм мәктәпкәчә яштәге балаларга, спорт-сәламәтләндерү юнәлешендәге башка оешмалар секцияләренә йөрүче, алар «Акчарлак» ССК» МБУ базасында һәрберсеннән 80 сумга кадәр уздырыла. Балалар бассейнына коллектив йөрүне озатып йөрүчеләр - һәркайсыннан 130 сум (зурлар).

**Льготалар (1 кешегә 1 сәгать дәвамлылык) «Акчарлак ССК»МБУ тренажер залына бару өчен 10:00 дән 22:00 сәгатькә кадәр бар:**

1. 14 яшьтән 16 яшькә кадәр балалар - 80 сум (уку урыныннан белешмә күрсәткәндә);

СССР территориясендә, Россия Федерациясе территориясендә һәм башка дәүләтләр территориясендә сугышчан хәрәкәтләр ветераннары - 100 сум;

4. Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнар - 100 сум;

5. Раслаучы документ һәм паспорт биргәндә пенсионерлар - 100 сум;

**Уен залына (аэробика залына, көрәш залына һәм күп функцияле залга) бару өчен ташламалар (1 кешегә 1 сәг.) социаль өлкәдә һәм физик культура һәм массакүләм спорт өлкәсендә эшләүче коммерциячел булмаган оешмаларга бирелә, «Акчарлак» ССК» МБУ базасында алар 10:00 сәгатьтән 22:00 сәгатькә кадәр күмәк дәресләр уздырганда:**

1. 4 яшьтән 16 яшькә кадәрге балалар 80 сум;

2. Өлкәннәр 130 сум;

**СВО (Махсус хәрби операция) катнашучыларының балалары өчен бассейн, тренажер залы, теннис (өстәл теннисы һәм зур теннис), бильярд хезмәтләре, билгеләнгән хезмәтләрнең прейскуранты нигезендә, бушлай күрсәтелә.**